| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>ЧУТЕЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЧҮТИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

9 ноябрь 2022 ел Чүти ав. № 21

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
*районынын* Чүти авылында
гражданнар жыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1.2022 елның 21 нояберенэ 13 сәг 00 минутка Чүти авылы Кооператив урамы,37 йорт адресы буенча урнашканавыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлегенең үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***беренче этабын*** билгеләргә.

2.2022 елның 22 нояберенэ 14 сәг 00 минутка Чүти авылы Гисматуллина урамы , 35 йорты адресы буенча урнашкан Чүти мәктәп бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлегенең үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***икенче этабын*** билгеләргә.

3.2022 елның 23 нояберенә 15 сәг 00 минутка Чүти авылы Куйбышев урамы,7 йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлегең үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***өченче этабын*** билгеләргә.

4. 2022 елның 24 нояберенэ 13 сәг 00 минутка Чүти авылы, Гисматуллина урамында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл жирлегең үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын билгеләргә.

5. 2022 елның 25 нояберенэ 14 сәг 00 минутка Чүти авылы Наримана урамында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл

җирлегенең үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***бишенче этабын*** билгеләргә.

6.2022 елның 26 нояберенэ 15 сәг 00 минутка Чүти авылы Кооперативная урамында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлегенең үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***алтынчы этабын*** билгеләргә.

7. 2022 елның 27 нояберенэ 13 сәг 00 минутка Чүти авылы Советская урамында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлегенең үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***җиденче этабын*** билгеләргә.

8. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны урыны буенча Чүти авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

*а)* ***җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:***

- материаллар сатып алып, урамнарны яктыртуны ремонтлау;
- авыл җирлеге торак пунктларындагы санкөиялэгэн һәм санкцияләнмәгән чүплекләр территориясен чистарту;
- материаллар сатып алып җәяүлеләр өчен күперләрне ремонтлау;

*б)* ***янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүне оештыру:***

- Олы Тәрбит авылында янгын сүндерү машинасын,җиһазларын,бүлмәләрен һәм ДПО хезмәткәрен тоту;

*в)* ***җирлектәге торак пунктлар чикләрендәге җирле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:***

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлектәге торак пунктлар чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

г)**җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру**:

-материаллар сатып алып,су челтәрләрен ремонтлау;

*д)* ***ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:***

- материаллар сатып алып, зиратларны чистарту һәм ремонтлау.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

9.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

10. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Республикасы Кайбыч муниципаль районының
Чүти авыл җирлеге Башлыгы П.П.Тараканов

Совет Чутеевского сельского поселения
Чүти авыл җирлеге Советы